АРБОР ТӨП БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ

# “ПИОНЕРЛАР ЭЗЕННӘН”

(Пионерия оешмасы барлыкка килүнең
100 еллыгына багышланган
уен-бәйге эшкәртмәсе)

Төзеде: Мифтахова Руфия Бильсур кызы,

2022

“Пионерлар эзеннән”

(Пионерия оешмасы барлыкка килүнең 100 еллыгына багышланган уен-бәйге)

Максат:

1. Укучыларда пионер оешмасы тарихы турында күзаллау булдыру.
2. Герой пионерлар батырлыгы белән таныштыру.
3. Җитезлек һәм белем таләп иткән бәйгеләрдә сынау.
4. Пионерлар үрнәгендә бөек эшләргә омтылыш, дуслык, бердәмлек хисләре тәрбияләү.

Катнашалар: 1-5 нче сыйныф укучылары (аерым сыйныф отрядлары белән үткәргә дә мөмкин)

Җиһазлау: презентация, быргы, барабан, галстук, әйләнә, инә-җеп, мәкальләр, төрле фигуралар, пазл итеп эшләнгән байрак рәсеме һб

Залны элеккеге пионер сборларындагыча җиһазландырырга мөмкин. Пионер атрибутлары-байрак, быргы, барабан, галстук һ.б. күргәзмә төзергә тәкъдим ителәә. Алып баручы педагог-оештыручы да, укучылар үзидарәсе лидеры да булырга мөмкин. Кичәнең беренче өлешен мәктәп музеенда уздыру отышы.

Бәйге барышы:

Алып баручы: Хәерле көн, минем нәни дусларым!

Бүген мин сезне гадәти булмаган уенга чакырам. “Пионерлар эзеннән” дип атадым мин бу уенны. Ә кемнәр соң ул пионерлар? Сезнең ишеткәнегез бармы? Әти-әниләрегезнең укучы вакыттагы фотосурәтләрен күргәнегез бармы? Уенның беренче өлешен без музейда үткәрербез.

Кичәнең беренче өлешен мәктәп музеенда уздыру отышлы.

Үткән гасырның 20 нче елларында бөтен халык яңа җәмгыять төзү белән шөгыльләнә. Илебез җитәкчеләре үзләренә яңа алмаш турында инде күптәннән уйланалар. Яшьләр берләшмәләре төзелүнең беренче көннәреннән үк зур

шәһәрләрдә балалар оешмалары күренә башлый. 1919 нчы елда Оренбург губернасы Мостафа авылында булачак шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил балалар оешмасы төзи һәм җитәкли. Бу оешма булачак пионер оешмасының башлангычы була. Һәм менә 1922 нче ел, май. Бөтенроссия яшьләр Конференциясе пионер отрядлары төзү турында карар кабул итә. В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының туган көне 1922 нче елның 19 мае санала. Бу көннән соң инде бер гасыр вакыт үткән. Кайчандыр пионер сафларында булганнар пионер тормышындагы кызыклы, истәлекле вакыйгаларны сагынып, горурланып искә алалар. Яшь буынга тарихны белү бик кирәк.

Шуңа да бүген без пионерия тарихы, пионерлар тормышы белән танышырбыз, алар уйнаган уеннарны уйнап, җитезлектә-зирәклектә көч сынашырбыз.

Музейда пионер киемнәре, значок, төрле атрибутлар, байрак, быргы һб экспонатлар турында кыскача таныштыру. Ленин портретын күрсәтү, аның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү.

- “Кайсы командага?”. Командаларга бүленеш: өстәлдән үзләре теләгән төстәге кәгазьләрне алалар, ә анда команда исеме язылган. Шул рәвешле барлык балалар да өч командага бүленеп бетә.
- “Нәрсә аңлата?” Әйдәгез, башта командаларның исеменә игътибар итик. «Быргы», «Барабан», «Галстук»- пионерларның алыштыргысыз атрибутлары булган.

Алып баручы: “Без һәрвакыт әзер!” – пионерларның лозунгсы бүгенге уенда сезнең дә девиз булсын. Мин ярышны аңлаткач, сез үз әзерлегегезне белдереп “Без һәрвакыт әзер!” дип җавап бирерсез.

Уен-бәйгебезне башлыйбыз. Сез әзерме?

Командалар “Без һәрвакыт әзер!” дип җавап бирә.

Ярышлар:

1. Иң беренче бәйге күпмедер танышу кебегрәк булыр. Сез үз командагызның символын яклагыз һәм девизын уйлап чыгарыгыз.
2. “Агач утырту”. Пионерлар табигатьне яклаучы, саклаучы булганнар. Бакчалар үстергәннәр, агачлар утыртканнар. Без дә агач утыртабыз. Бирелгән түгәрәкләр эченә кайсы команда беренче булып “агач” утыртып бетерә. Сез әзерме?
3. “Мәкальнең дәвамын табу». Пионерлар – бик дус һәм тату балалар. Сез дә бергәләшеп дуслык турындагы мәкальләрне табыгыз әле.
4. Ә хәзер ял итеп алабыз. Пионерлар күмәк уеннар уйнарга яратканнар. Без дә сезнең белән халкыбызның элек-электән яратып уйналган “Бишле” уенына тукталырбыз.
5. “Герой пионер батырлыгы” турында сөйләргә әзерлек – укучыларга өй эше итеп бирелгән иде. Әзерләнгән укучыларны барлагыз, кабатланырга тиеш түгел. (Леня Голиков, Зина Портной, Марат Казей һб)
6. “Һөнәрле бала” бәйгесе дә безгә пионерлар заманыннан ук килгән, чөнки алар һәрчак өлкәннәргә ярдәм иткәннәр, төрле һөнәрләргә өйрәнгәннәр. Сез дә төймә тагып күрсәтегез әле. Кемнең эше иң тиз, чиста, пөхтә башкарылыр икән?! Сез әзерме?
7. Пионерлар нинди генә кыен хәлдә калсалар да, чыгу юлын таба алучы кыю һәм зирәк балалар булган. Киләсе бәйгедә сезнең дә зирәклек чагыла. Һәр командадан берәр бала күзе бәйләгән килеш идәннән төрле фигураларны танып җыярга тиеш (түгәрәк, шакмак, өчпочмак)
8. Музыкаль тәнәфес. Әйдәгез, бергәләшеп җырлап алыйк. Караокега җыр
9. Пионерлар үз туган якларының ялкынлы патриотлары булганнар. Сез дә патриотлар, ягъни үз туган җирләрен яхшы белүче, яратучы балалармы икән – алдагы уеныбызда шуны тикшереп алыйк. Уен “Таныйсызмы?” дип атала. Слайдта чыккан кешеләрнең исем-фамилияләрен һәм кем булуларын, ә географик урыннарның атамаларын белергә кирәк (Муса Җәлил, Тукай, Илһам Шакиров,

Р.Миннеханов, А.Хәйретдинов һб фотолары; авылның чишмә, урман, куаклык сурәтләре слайтта чиратлаштырылып чыгарыла)

10. “Байрак табу”. Пионерлар заманыннан безнең көннәргә кадәр килеп җиткән мавыктыргыч та, физик ныклык та таләп итә торган уен -”Аҗаган” уенын без һәр ел саен яратып уйныйбыз. “Аҗаган” байрак табу белән тәмамлана. Без дә бүгенге уенны байрак табу белән төгәлләрбез. Әлбәттә, “байрак”ны мин кар астына яшермәде, сезгә бары тик бирелгән пазллардан байрак рәсемен төзергә генә кирәк.

19 май – Пионерия туган көн. В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасы Якты хатирәләр белән тарихка кереп калган оешмага быел 100 ел тула.

Узган гасырның 80нче елларына кадәр туучыларга кызыл галстук һәм пионер значогы тагып, быргы тавышына сборларга җыелып, җәмгыять эшләрендә актив катнашып, өлкәннәргә ярдәмләшеп, кечеләрнешефлыкка алып, учак янында хәрби-патриотик җырлар җырлап, бик кызыклы чорда яшәргә туры килгән. Әлеге оешма Туган илне яратырга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә, дус һәм бердәм булырга, хезмәткә өйрәткән. Пионерлар сафына керү өчен укуда тырыш,төрле чараларда актив булырга кирәк булган. Заманалар үзгәрсә дә, без – эзтабарлар яки варислар булсак та, әлеге кыйммәтләр үзгәрмәгән. Без дә тырыш, акыллы, белемле, кызыксынучан булырга омтылырга тиеш. Туган авылыбыз, туган район һәм республикабызны яратырга, аларның чын лаеклы гражданнары булып үсәргә тиешбез.

Бүгенге кичәдән сез пионерлар турында күп мәгълүмат алгансыз дип ышанам. Катнашкан командаларга зур рәхмәт, ә хәзер нәтиҗәләр ясау өчен сүз ЖЮРИ га бирелә.

ЖЮРИ нәтиҗәләре. Бүләкләү.

Командаларга “Иң зирәк”, “Иң кыю”, “Иң җитез” номинацияләре буенча вымпеллар тапшырыла.

Әлеге сценарий буенча мәктәптә кичә үткәрелде. Кичә барышы кушымтада бирелә.

Кушымта














220 В


БАРАБАН


Марат Казей


Леня Голиков
Юный Леня Голиков напал на автомобиль немецкого генерала Рихарда Витца, застрелил генерала и добыл документы, с чертежами и описанием новых образцов немецких мин, инспекционные донесения командованию, карты-схемы минных полей и другие важные бумаги военного характера. За этот подвиг Лёня Голиков был представлен к высшей правительственной награде - медали «Золотая звезда» и званию Героя Советского Союза.

















36-42 В
220 В


ИН КЫЮ
КОМАНДА

